**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Алькеевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки**
**муниципаль районы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
тел: : 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

**2020 елның 20 марты** **138№**

**Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 5 февралендәге «Гражданнарның яшәве өчен яраклы һәм күпфатирлы йорт авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле торак бина итеп тану турында ведомствоара комиссия төзү турында» 18 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы "Урынны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турындагы Нигезләмәне һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип раслау турында" 47 номерлы карары (2015 елның 25 мартыннан 269 № үзгәрешләр белән) нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Урынны яшәү өчен яраклы торак бина, торак урынын авария хәлендәге һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йорт дип тану турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 кисәкнең 2 пунктында «Татарстан Республикасы» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе яисә Россия Федерациясе субъекты милкендә булган күпфатирлы йортлардан, барлык торактан тыш» сүзләрен өстәргә;

- 2 нче кушымтаның 17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"17. Күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану өчен нигез ул күпфатирлы йортның җимерелү сәләте һәм куркынычы бетүне таныклаучы, аларның җимерелүләре һәм деформацияләре белән характерлана торган, аның карамагында булган төзелеш конструкцияләренең (конструкцияләренең) яки тулаем күпфатирлы йортның авария хәлендәге техник торышы һәм (яисә) күпфатирлы йортның тотрыклылыгын югалтырга мөмкин креннар булып тора.

Әгәр күпфатирлы йорт авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип табылса, мондый күпфатирлы йортта урнашкан торак биналар яшәү өчен яраксыз дип санала.”.

- 22 пунктта “яки дәүләт күзәтчелеге (контроль) органнарының үз компетенцияләренә кертелгән мәсьәләләр буенча бәяләмәсе нигезендә," сүзләрен“яки дәүләт күзәтчелеге (контроль) органнарының үз компетенцияләренә кертелгән мәсьәләләр буенча бәяләмәсе нигезендә, яки Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 21 августындагы Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан гражданнарның торак урыннарына китерелгән зыянны ирекле иминләштерү механизмын кулланып, зыянны каплауны оештыру программасы кысаларында кире кайтарылырга тиешле зыян күләмен билгеләү методикасы, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчалары исәбеннән бирелә торган акчаларны иминият һәм ярдәм хисабына ирекле иминләштерү механизмын кулланып, сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле торак йорт һәм бакча йортын торак йорт белән һәм торак бинаны, күпфатирлы йорттагы торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турындагы Нигезләмә” 1082 номерлы карары нигезендә торак бинага экспертиза үткәрү кагыйдәләрен раслау турында" сүзләренә алмаштырырга,”

- 2 нче кушымтаның 4 кисәгендәге 28 пунктта "яки дәүләт күзәтчелеге (контроле) органы бәяләмәсе" сүзләрен “яки дәүләт күзәтчелеге (контроль) органы бәяләмәсе, яки әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегенең 22 пунктында каралган торак урыны экспертизасы” сүзләренә алмаштырырга.

- 4 кисәгендәге 24 пунктның 2 абзацында “шулай ук әлеге Нигезләмәнең 4 кисәгендәге 22 пунктында каралган башка документлар” сүзләрен өстәргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Интернет - телекоммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында http://alkeevskiy.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче: Юсупов И.В.